**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

# О порядке формирования лицензионной комиссии Республики Татарстан по лицензированию деятельности по управлению многоквартирными домами

В соответствии со статьей 201 Жилищного кодекса Российской Федерации и приказом Министерства строительства и жилищно-коммунального хозяйства Российской Федерации от 17 августа 2016 года № 570/пр «Об утверждении Методических указаний о порядке формирования и деятельности лицензионной комиссии для обеспечения деятельности органов государственного жилищного надзора по лицензированию деятельности по управлению многоквартирными домами в субъекте Российской Федерации» **постановляю:**

1. Определить Государственную жилищную инспекцию Республики Татарстан исполнительным органом государственной власти Республики Татарстан, уполномоченным на проведение организационных мероприятий по формированию лицензионной комиссии Республики Татарстан по лицензированию деятельности по управлению многоквартирными домами и организационно-техническое обеспечение ее деятельности.

2. Утвердить прилагаемое Положение о порядке формирования лицензионной комиссии Республики Татарстан по лицензированию деятельности по управлению многоквартирными домами (далее – Положение).

3. Государственной жилищной инспекции Республики Татарстан:

осуществить формирование лицензионной комиссии Республики Татарстан по лицензированию деятельности по управлению многоквартирными домами в соответствии с Положением, утвержденным настоящим Указом;

в 25-дневный срок внести в установленном порядке проект указа Президента Республики Татарстан о лицензионной комиссии Республики Татарстан по лицензированию деятельности по управлению многоквартирными домами.

4. Контроль за исполнением настоящего Указа возложить на Кабинет Министров Республики Татарстан.

5. Настоящий Указ вступает в силу со дня его подписания.

**Президент**
**Республики Татарстан** **Р.Н. Минниханов**

Казань, Кремль
05 апреля 2018 года
№ УП-285

Приложение
к Указу Президента
Республики Татарстан

от «05» апреля 2018 года

№ УП-285

**Положение**
**о порядке формирования лицензионной комиссии Республики Татарстан по лицензированию деятельности по управлению многоквартирными домами**

1. Настоящее Положение определяет порядок формирования лицензионной комиссии Республики Татарстан по лицензированию деятельности по управлению многоквартирными домами (далее – лицензионная комиссия).

2. Организационные мероприятия по формированию лицензионной комиссии осуществляет Государственная жилищная инспекция Республики Татарстан (далее – Инспекция).

3. Лицензионная комиссия формируется в составе 15 членов, включая председателя, заместителя председателя и секретаря.

4. Состав лицензионной комиссии формируется из числа кандидатов, соответствующих требованиям, установленным настоящим Положением, а также с учетом предусмотренных для представителей квот и критериев отбора.

5. В состав лицензионной комиссии включаются представители:

а) саморегулируемых организаций в сфере управления многоквартирными домами – три представителя;

б) общественных объединений, иных некоммерческих организаций, указанных в части 8 статьи 20 Жилищного кодекса Российской Федерации, уставная деятельность которых связана с управлением многоквартирными домами, – два представителя;

в) Государственного Совета Республики Татарстан – один представитель;

г) Кабинета Министров Республики Татарстан – один представитель;

д) Министерства строительства, архитектуры и жилищно-коммунального хозяйства Республики Татарстан – два представителя;

е) Государственной жилищной инспекции Республики Татарстан – два представителя;

ж) Совета муниципальных образований Республики Татарстан – один представитель;

з) Управления Президента Республики Татарстан по вопросам антикоррупционной политики – один представитель (с правом совещательного голоса);

и) Уполномоченного при Президенте Республики Татарстан по защите прав предпринимателей – один представитель;

к) Общественной палаты Республики Татарстан – один представитель.

6. В состав лицензионной комиссии включаются лица, имеющие гражданство Российской Федерации.

7. В состав лицензионной комиссии не включаются лица:

а) признанные судом недееспособными или ограниченно дееспособными;

б) состоящие на учете в наркологическом или психоневрологическом диспансере в связи с лечением от алкоголизма, наркомании, токсикомании, хронических и затяжных психических расстройств;

в) имеющие неснятую или непогашенную судимость;

г) подвергнутые административному наказанию в виде дисквалификации;

д) состоящие в отношениях родства (свойства) с руководителем Инспекции.

8. Инспекция в течение двух рабочих дней со дня издания указа Президента Республики Татарстан о порядке формирования лицензионной комиссии размещает на своем официальном сайте в информационно-телекоммуникационной сети «Интернет» (далее – официальный сайт):

порядок подачи заявлений о включении в состав лицензионной комиссии;

форму заявления о включении в состав лицензионной комиссии и перечень документов, прилагаемых к заявлению;

порядок размещения на официальном сайте Инспекции информации о поданных заявлениях кандидатов, претендующих на включение в состав лицензионной комиссии, определенный пунктом 12 настоящего Положения;

информацию, уточняющую порядок и критерии принятия решения о создании лицензионной комиссии, в том числе предусмотренную пунктом 18 настоящего Положения.

9. Заявления о включении в состав лицензионной комиссии подаются в порядке и по форме согласно приложениям № 1 и 2 к настоящему Положению.

10. Прием заявлений о включении в состав лицензионной комиссии осуществляется Инспекцией в течение 10 рабочих дней начиная со дня, следующего за днем размещения на ее официальном сайте информации, предусмотренной пунктом 8 настоящего Положения.

11. В случае если заявление кандидата оформлено с нарушением установленных требований и (или) прилагаемые к нему документы представлены не в полном объеме, лицо, ответственное за прием документов, направляет кандидату уведомление о необходимости устранения выявленных нарушений и (или) представления отсутствующих документов в течение пяти

рабочих дней с даты поступления заявления кандидата, но не позднее последнего дня приема документов. Соответствующее уведомление направляется в течение двух рабочих дней со дня выявления указанных обстоятельств.

12. Инспекция формирует список кандидатов в состав лицензионной комиссии и размещает его на своем официальном сайте с указанием информации о кандидатах, предусмотренной пунктом 14 Методических указаний о порядке формирования и деятельности лицензионной комиссии для обеспечения деятельности органов государственного жилищного надзора по лицензированию деятельности по управлению многоквартирными домами в субъекте Российской Федерации, утвержденных приказом Министерства строительства и жилищно-коммунального хозяйства Российской Федерации от 17 августа 2016 года № 570/пр.

Список кандидатов в состав лицензионной комиссии обновляется Инспекцией не реже одного раза в три рабочих дня на основании поступивших от заявителей документов.

13. Инспекция осуществляет проверку полноты и достоверности сведений, содержащихся в заявлении и прилагаемых к нему документах, а также отсутствия оснований, препятствующих включению кандидата в состав лицензионной комиссии, в течение пяти рабочих дней после дня окончания срока приема заявлений.

14. Инспекция направляет кандидату письменный отказ во включении в состав лицензионной комиссии в течение двух рабочих дней после завершения проверки документов по следующим основаниям:

а) кандидат не отвечает требованиям, установленным пунктами 6 и 7 настоящего Положения;

б) на момент завершения приема документов кандидат не представил полный комплект необходимых документов.

15. Проверка отсутствия оснований, препятствующих включению кандидата в состав лицензионной комиссии, осуществляется в том числе с использованием межведомственного информационного взаимодействия.

16. В течение трех рабочих дней со дня окончания срока приема заявлений Инспекция формирует итоговый список кандидатов в члены лицензионной комиссии на основе поданных заявлений и размещает его в открытом доступе на своем официальном сайте.

17. Инспекция направляет Президенту Республики Татарстан итоговый список кандидатов в члены лицензионной комиссии не позднее рабочего дня, следующего за днем окончания срока, установленного пунктом 16 настоящего Положения.

18. В случае если в итоговом списке кандидатов в состав лицензионной комиссии от саморегулируемых организаций в сфере управления многоквартирными домами указано большее количество кандидатов, соответствующих установленным требованиям, чем может быть включено в состав лицензионной комиссии с учетом квот, установленных пунктом 5 настоящего Положения, приоритет при формировании состава лицензионной

комиссии имеют кандидаты, представившие рекомендательное письмо ассоциации (союза) саморегулируемых организаций, уставная деятельность которых связана с управлением многоквартирными домами, а при невозможности представления такого приоритета – в соответствии с абзацем вторым настоящего пункта.

Иные кандидаты, указанные в итоговом списке кандидатов, включаются в состав лицензионной комиссии в порядке очередности в зависимости от даты и времени поступления заявлений с учетом квот, установленных пунктом 5 настоящего Положения.

19. В случае если на день окончания срока приема заявлений количество заявившихся кандидатов, соответствующих требованиям, установленным настоящим Положением, недостаточно для формирования лицензионной комиссии, Инспекция в течение трех рабочих дней с даты окончания срока приема заявлений повторно организует проведение мероприятий по формированию лицензионной комиссии в порядке, установленном настоящим Положением.

20. Положение о лицензионной комиссии и ее состав утверждаются указом Президента Республики Татарстан.

21. Не позднее рабочего дня, следующего за днем принятия решения о создании лицензионной комиссии, Инспекция направляет в адрес кандидатов уведомление о включении в состав лицензионной комиссии или об отказе во включении в состав лицензионной комиссии с мотивированным обоснованием такого отказа.

Приложение № 1
к Положению о порядке
формирования лицензионной
комиссии Республики Татарстан
по лицензированию
деятельности по управлению
многоквартирными домами

**Порядок**
**подачи заявлений о включении в состав лицензионной комиссии Республики Татарстан по лицензированию деятельности по управлению многоквартирными домами**

1. Настоящий Порядок определяет процедуру подачи кандидатами заявлений о включении в состав лицензионной комиссии Республики Татарстан по лицензированию деятельности по управлению многоквартирными домами (далее - лицензионная комиссия).

2. Заявление о включении в состав лицензионной комиссии (далее – заявление) с приложением необходимых документов подается кандидатом на имя Президента Республики Татарстан в Государственную жилищную инспекцию Республики Татарстан (далее – Инспекция).

3. Кандидатами, являющимися представителями саморегулируемых организаций в сфере управления многоквартирными домами и общественных объединений, иных некоммерческих организаций, указанных в части 8 статьи 20 Жилищного кодекса Российской Федерации, уставная деятельность которых связана с управлением многоквартирными домами, к заявлению прилагаются следующие документы:

а) копия документа об образовании и о квалификации, подтверждающего высшее образование;

б) копии документов о дополнительном профессиональном образовании или профессиональной переподготовке в сфере жилищно-коммунального хозяйства (при наличии);

в) копия приказа (распоряжения) работодателя о приеме на работу в организацию, представителем которой является кандидат;

г) копии документов, подтверждающих наличие стажа работы в сфере жилищно-коммунального хозяйства за последние два года (копия страниц трудовой книжки или копии приказов (распоряжений) о приеме на работу);

д) выписка из Единого государственного реестра юридических лиц;

е) рекомендательное письмо ассоциации (союза) саморегулируемых организаций, уставная деятельность которых связана с управлением многоквартирными домами, - для кандидатов, являющихся представителями саморегулируемых организаций (при наличии).

Вышеуказанные копии документов представляются в Инспекцию с предъявлением оригинала.

4. Кандидатами, являющимися представителями органов государственной власти Республики Татарстан, Совета муниципальных образований Республики Татарстан, Управления Президента Республики Татарстан по вопросам антикоррупционной политики, Уполномоченного при Президенте Республики Татарстан по защите прав предпринимателей, Общественной палаты Республики Татарстан, к заявлению прилагается письменное согласие соответствующего руководителя (должностного лица) о включении кандидата в состав лицензионной комиссии.

5. Заявление подается кандидатом в письменной форме либо направляется в Инспекцию с использованием информационно-телекоммуникационных технологий в электронной форме на электронный адрес Инспекции. При направлении заявления с приложением необходимых документов в форме электронного документа все документы должны быть подписаны электронной подписью в соответствии с законодательством Российской Федерации.

6. Местонахождение Инспекции и ее почтовый адрес: 420111, Республика Татарстан, г. Казань, ул. Большая Красная, д. 15/9.

7. График, в соответствии с которым осуществляется прием заявлений от кандидатов, лицо, ответственное за прием заявлений, контактная информация о нем, а также адрес электронной почты, на который могут быть направлены заявления, определяются Инспекцией и размещаются на ее официальном сайте.

8. Заявление и прилагаемые к нему документы принимаются по описи, копия которой с отметкой о дате приема заявления и документов в день приема вручается кандидату или направляется ему в электронной форме в случае получения соответствующего согласия кандидата.

Приложение № 2
к Положению о порядке
формирования лицензионной
комиссии Республики Татарстан
по лицензированию
деятельности по управлению
многоквартирными домами

Форма

Президенту Республики Татарстан
______________________________

от____________________________
(фамилия, имя, отчество (при наличии)
______________________________
кандидата)

Заявление
о включении в состав лицензионной комиссии Республики Татарстан по лицензированию деятельности по управлению многоквартирными домами

Прошу включить меня, ______________________________________
(фамилия, имя, отчество (при наличии),
________________________________________________________________
дата и место рождения, паспортные данные (серия, номер, кем и когда выдан)
________________________________________________________________,
в состав лицензионной комиссии Республики Татарстан по лицензированию деятельности по управлению многоквартирными домами.

Сведения об образовании и повышении квалификации: ____________
(наименование
________________________________________________________________
образовательной организации высшего образования и полученная квалификация,
________________________________________________________________
уровень образования, срок прохождения учебы, реквизиты документов, подтверждающих
________________________________________________________________.
наличие высшего образования, дополнительного образования или переподготовки)

Стаж работы в сфере жилищно-коммунального хозяйства___________.

Являюсь представителем ___________________________________
(полное наименование организации)
________________________________________________________________.

Подтверждаю, что не признан судом недееспособным или ограниченно дееспособным, не состою на учете в наркологическом или психоневрологическом диспансере в связи с лечением от алкоголизма, наркомании, токсикомании, хронических и затяжных психических

расстройств, не имею неснятую или непогашенную судимость, не подвергнут административному наказанию в виде дисквалификации, не состою в отношениях родства (свойства) с руководителем Государственной жилищной инспекции Республики Татарстан.

Контактная информация:_______________________________________
(телефон, факс, почтовый адрес,

______________________________________________________________.
адрес электронной почты (при наличии)

Выражаю согласие на автоматизированную, а также без использования средств автоматизации обработку моих персональных данных в соответствии со статьей 9 Федерального закона от 27 июля 2006 года № 152-ФЗ «О персональных данных».

На получение в электронной форме информации по вопросам рассмотрения настоящего заявления согласен (адрес электронной почты: ______________________) / не согласен (нужное подчеркнуть).

«___»_________________года /__________/____________________/
(дата) (подпись, расшифровка подписи)

___________

**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

**Күпфатирлы йортларга идарә итү эшчәнлеген лицензияләү буенча Татарстан Республикасы лицензия комиссиясен формалаштыру тәртибе турында**

Россия Федерациясе Торак кодексының 201 статьясы һәм Россия Федерациясе Төзелеш һәм торак-коммуналь министрлыгының «Россия Федерациясе субъектында күпфатирлы йортларга идарә итү эшчәнлеген лицензияләү буенча дәүләт торак күзәтчелеге органнары эшчәнлеген тәэмин итү өчен лицензия комиссиясен формалаштыруның һәм аның эшчәнлегенең тәртибе турында методик күрсәтмәләрне раслау хакында» 2016 елның 17 августындагы 570/пр номерлы боерыгы нигезендә **карар бирәм:**

1. Күпфатирлы йортларга идарә итү эшчәнлеген лицензияләү буенча Татарстан Республикасы лицензия комиссиясен формалаштыру буенча оештыру чараларын уздыру һәм аның эшчәнлеген оештыру-техник тәэмин итү вәкаләте бирелгән Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органы буларак Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясен билгеләргә.

2. Күпфатирлы йортларга идарә итү эшчәнлеген лицензияләү буенча Татарстан Республикасы лицензия комиссиясен формалаштыру тәртибе турында кушымтада бирелүче нигезләмәне (алга таба – Нигезләмә) расларга.

3. Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясенә:

әлеге Указ белән расланган Нигезләмәгә таянып Күпфатирлы йортларга идарә итү эшчәнлеген лицензияләү буенча Татарстан Республикасы лицензия комиссиясен формалаштыруны гамәлгә ашырырга;

25 көн эчендә билгеләнгән тәртиптә Күпфатирлы йортларга идарә итү эшчәнлеген лицензияләү буенча Татарстан Республикасы лицензия комиссиясе турында Татарстан Республикасы Президенты указы проектын карауга кертергә.

4. Әлеге Указның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына йөкләргә.

5. Әлеге Указ аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты** **Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2018 ел, 05 апрель
№ ПУ-285

Татарстан Республикасы
Президентының
2018 елның «05» апрелендәге
ПУ-285 номерлы Указына
кушымта

**Күпфатирлы йортларга идарә итү эшчәнлеген лицензияләү буенча Татарстан Республикасы лицензия комиссиясен формалаштыру тәртибе турында**

1. Әлеге Нигезләмә Күпфатирлы йортларга идарә итү эшчәнлеген лицензияләү буенча Татарстан Республикасы лицензия комиссиясен (алга таба – лицензия комиссиясе) формалаштыру тәртибен билгели.

2. Лицензия комиссиясе формалаштыру буенча оештыру чараларын Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясе (алга таба – Инспекция) башкара.

3. Лицензия комиссиясе рәис, рәис урынбасары һәм секретарьны кертеп 15 әгъза составында формалаштырыла.

4. Лицензия комиссиясе составы әлеге Нигезләмәгә таянып билгеләнгән тиешле таләпләргә туры килә торган кандидатлар арасыннан, шулай ук вәкилләр өчен анда каралаган квоталарны һәм сайлап алу критерийларын исәпкә алып формалаштырыла.

5. Лицензия комиссиясе составына түбәндәгеләрнең вәкилләре кертелә:

а) күпфатирлы йортларга идарә итү өлкәсендә үзкөйләнешле оешмалардан – өч вәкил;

б) Россия Федерациясе Торак кодексының 20 статьясының 8 кисәгендә күрсәтелгән иҗтимагый берләшмәләр, коммерциячел булмаган оешмалардан – ике вәкил;

в) Татарстан Республикасы Дәүләт Советыннан – бер вәкил;

г) Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетыннан – бер вәкил;

д) Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгыннан – ике вәкил;

е) Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясе – ике вәкил;

ж) Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләр советы – бер вәкил;

з) Татарстан Республикасы Президентының Коррупциягә каршы сәясәт мәсьәләләре буенча идарәсеннән – бер вәкил (киңәшмә тавышы хокукы белән);

и) Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Эшкуарлар хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкилдән – бер вәкил;

к) Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасыннан – бер вәкил.

6. Лицензия комиссиясе составына Россия Федерациясе гражданлыгы булган затлар кертелә.

7. Лицензия комиссиясе составына түбәндәгеләр кертелми:

а) суд тарафыннан хокуктан файдалануга сәләтсез яисә хокуктан файдалануга сәләте чикле дип табылган затлар;

б) алкоголизмнан, наркоманлыктан, токсикоманлыктан, хроник һәм озакка сузылган психик чирләрдән дәвалану белән бәйле рәвештә наркология һәм психоневрология диспансерында исәптә торган затлар;

в) туктатылмаган һәм ябылмаган суд хөкеме астында булган затлар;

г) дисквалификация рәвешендә административ җәзага тартылган затлар;

д) Инспекция җитәкчесе белән туганлык мөнәсәбәтләрендә торучы затлар.

8. Инспекция Татарстан Республикасы Президентының Күпфатирлы йортларга идарә итү эшчәнлеген лицензияләү буенча Татарстан Республикасы лицензия комиссиясен формалаштыру тәртибе турында указы чыгарылган көннән ике эш көне эчендә «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында (алга таба – рәсми сайт) түбәндәгеләрне урнаштыра:

лицензия комиссиясе составына кертү турында гаризалар бирү тәртибе;

лицензия комиссиясе составына кандидатларны кертү турындагы гариза формасы һәм гаризага теркәлүче документлар исемлеге;

Инспекциянең рәсми сайтында әлеге Нигезләмәнең 12 пункты белән билгеләнгән лицензия комиссиясе составына кертелергә теләк белдергән кандидатлар тарафыннан бирелгән гаризалар турындагы мәгълүматны урнаштыру тәртибе;

лицензия комиссиясен булдыру турында, шул исәптән әлеге Нигезләмәнең 18 пунктында каралган карар кабул итү тәртибен һәм критерийларына тәгаллек кертә торган мәгълүматны.

9. Лицензия комиссиясе составына кандидатларны кертү турындагы гаризалар әлеге Нигезләмәгә 1 нче һәм 2 нче кушымталар нигезендә билгеләнә торган тәртиптә һәм формада бирелә.

10. Лицензия комиссиясе составына кандидатларны кертү турындагы гаризаларны кабул итү Инспекция тарафыннан әлеге Нигезләмәнең 8 пунктында каралган мәгълүматны аның рәсми сайтында урнаштырганның икенче көненнән башлап 10 эш көне дәвамында башкарыла.

11. Әгәр кандидатның гаризасы билгеләнгән таләпләрне бозып тутырылган я (яисә) аңа теркәп бирелә торган документлар тулысынча бирелмәгән булса, кандидатлар гаризалары алынган датадан биш эш көне эчендә, әмма документларны кабул итүнең соңгы көненнән дә кичекмичә документларны кабул итү өчен җаваплы зат кандидатка ачыкланган җитешсезлекләрне бетерү я (яисә) булмаган документларны тапшыру

кирәклеге турында хәбәрнамә җибәрә. Мондый хәбәрнамә әлеге шартлар ачыкланган көннән ике эш көне эчендә җибәрелә.

12. Инспекция кандидатлар исемлеген формалаштыра һәм аны үзенең рәсми сайтында кандидатлар турында Россия Федерациясе Төзелеш һәм торак-коммуналь министрлыгының 2016 елның 17 августындагы 570/пр номерлы боерыгы нигезендә расланган Россия Федерациясе субъектларында күпфатирлы йортларга идарә итү эшчәнлеген лицензияләү буенча дәүләт торак күзәтчелеге органнары эшчәнлеген тәэмин итү өчен лицензия комиссиясен формалаштыруның һәм аның эшчәнлегенең тәртибе турында методик күрсәтмәләрнең 14 пунктында каралган мәгълүматны күрсәтеп урнаштыра.

Лицензия комиссиясе составына кандидатлар исемлеге Инспекция тарафыннан гариза бирүчеләрдән кергән документлар нигезендә кимендә өч эш көненә бер тапкыр яңартыла.

13. Инспекция гаризада һәм аңа теркәп бирелә торган документларда белешмәләрнең тулылыгын һәм дөреслеген, шулай ук кандидатны лицензия комиссиясе составына кертүгә каршылык тудыручы нигезләр булмауны гаризаларны кабул итү срогы тәмамланганнан соң биш эш көне эчендә тикшерә.

14. Түбәндәге нигезләр булганда, Инспекция кандидатка документларны тикшерү тәмамланганнан соң ике эш көне эчендә лицензия комиссиясе составына кертүдән баш тарту турында язма хәбәр җибәрә:

а) кандидат әлеге Нигезләмәнең 6 һәм 7 пунктларында билгеләнгән таләпләргә туры килми;

б) документлар кабул итү тәмамланган вакытка кандидат тиешле документларны биреп бетермәгән.

15. Кандидатны лицензия комиссиясе составына кертүгә каршылык тудыручы нигезләр булмауны тикшерү шул исәптән ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлектән файдаланып та башкарыла.

16. Гаризалар кабул итү срогы тәмамланганнан соң өч эш көне эчендә Инспекция бирелгән гаризалар нигезендә лицензия комиссиясенә әгъзалыкка йомгаклау исемлеген формалаштыра һәм аны үз рәсми сайтында һәркем файдаланырлык итеп урнаштыра.

17. Инспекция Татарстан Республикасы Президентына лицензия комиссиясенә әгъзалыкка йомгаклау исемлеген әлеге Нигезләмәнең 16 пунктында билгеләнгән вакыт тәмамланган көннән соң килә торган эш көненнән дә соңга калмыйча җибәрә.

18. Әгәр кандидатларның йомгаклау исемлегендә күпфатирлы йортларга идарә итү буенча үзкөйләнешле оешмалардан әлеге Нигезләмәнең 5 пунктында билгеләнгән квоталарны исәпкә алып лицензия комиссиясе составына кертелә ала торганнан артыграк билгеләнгән тәртипләргә туры килә торган кандидат күрсәтелсә, лицензия комиссиясе составын формалаштырганда устав эшчәнлеге күпфатирлы йортларга идарә итү белән бәйләнгән үзкөйләнешле оешмалар ассоциациясеннән (берлегеннән)

тәкъдим хаты биргән кандидатларга өстенлек бирелә, ә мондый өстенлекне бирү мөмкин булмаганда, әлеге абзацның икенче пункты нигезендә эш йөртелә.

Кандидатларның йомгаклау исемлегендә күрсәтелгән башка кандидатлар лицензия комиссиясе составына әлеге Нигезләмәнең 5 пунктында билгеләнгән квоталарны исәпкә алып гаризалар бирелгән датага һәм вакытка бәйле рәвештә чират тәртибендә кертелә.

19. Әгәр гаризаларны кабул итү вакыты тәмамланган көнгә таләпләргә туры килә торган гаризалар биргән кандидатларның саны лицензия комиссиясен формалаштыру өчен җитәрлек түгел икән, гаризаларны кабул итү вакыты тәмамланган вакыттан өч эш көне эчендә Инспекция әлеге Нигезләмәдә билгеләнгән тәртиптә лицензия комиссиясен формалаштыру буенча чаралар уздыруны кабаттан оештыра.

20. Лицензия комиссиясе турында нигезләмә һәм аның составы Татарстан Республикасы Президенты указы нигезендә раслана.

21. Лицензия комиссиясе төзү турында карар кабул ителгән көннән соң килә торган эш көненнән дә соңга калмыйча Инспекция кандидатлар адресына лицензия комиссиясе составына кертү яисә комиссиясе составына кертүдән дәлилләр нигезендә расланган баш тарту турында хәбәр җибәрә.

Күпфатирлы йортларга идарә итү
эшчәнлеген лицензияләү буенча
Татарстан Республикасы
лицензия комиссиясе
формалаштыру тәртибе
турында нигезләмәгә
1 нче кушымта

**Күпфатирлы йортларга идарә итү эшчәнлеген лицензияләү буенча Татарстан Республикасы лицензия комиссиясе составына кертүгә гариза бирү тәртибе**

1. Әлеге Тәртип кандидатлар тарафыннан күпфатирлы йортларга идарә итү эшчәнлеген лицензияләү буенча Татарстан Республикасы лицензия комиссиясе (алга таба – лицензия комиссиясе) составына кертү турында гариза бирү процедурасын билгели.

2. Лицензия комиссиясе составына кертү турында гариза (алга таба – гариза) һәм аңа теркәп бирелә торган тиешле документлар кандидат тарафыннан Татарстан Республикасы Президенты исеменә языла һәм Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясенә (алга таба – Инспекция) бирелә.

3. Күпфатирлы йортларга идарә итү өлкәсендә үзкөйләнешле оешмалар һәм җәмәгать берләшмәләре, Россия Федерациясе Торак кодексының 20 статьясы 8 өлешендә күрсәтелгән, устав эшчәнлеге күпфатирлы йортларга идарә итү белән бәйле булган башка коммерция оешмалары гаризага түбәндәге документларны теркәп бирә:

а) кандидатның югары белемен раслаучы югары белем алу һәм квалификациясе турында документның күчермәсе;

б) торак-коммуналь хуҗалыгы өлкәсе буенча өстәмә һөнәри белем алуы һәм һөнәри яктан яңадан әзерләү узуы турында документларның күчермәләре (булган очракта);

в) оешма вәкиле булып торучы кандидатны эшкә алу турында карарның (боерык) күчермәсе;

г) соңгы ике елга торак-коммуналь хуҗалыгы өлкәсендә эш стажы булуын раслаучы документларның күчермәсе (хезмәт кенәгәсе яисә эшкә алу турында карар (боерык) күчермәсе);

д) Юридик затларның Бердәм дәүләт реестрыннан күчермә;

е) үзкөйләнешле оешмалар вәкиле булып торучы кандидатлар өчен – устав эшчәнлеге күпфатирлы йортларга идарә итү белән бәйле булган үзкөйләнешле оешмалар ассоциациясенең (берлегенең) бәяләмә хаты (булган очракта).

Әлеге документларның күчермәләре Инспекциягә төп нөсхәләр белән бергә бирелә.

4. Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары, Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләр советы, Татарстан Республикасы Президентының Коррупциягә каршы сәясәт мәсьәләләре идарәсе, Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Эшкуарлар хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкил, Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы вәкилләре булып торучы кандидатлар гаризага тиешле җитәкченең (вазыйфаи затның) кандидатны лицензия комиссиясе составына кертүгә язмача ризалыгын теркәп бирә.

5. Гаризаны кандидат язма рәвештә бирелә яисә мәгълүмат-телекоммуникация технологияләрен файдаланып, Инспекциянең электрон адресына электрон рәвештә җибәрелә. Гаризаны һәм аңа теркәп бирелә торган тиешле документларны электрон документ рәвешендә җибәргән очракта, барлык документларга да Россия Федерациясе законнары нигезендә электрон имза куелырга тиеш.

6. Инспекциянең урнашкан урыны һәм аның почта адресы: 420111, Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Зур Кызыл урамы, 15/9 йорт.

7. Кандидатларның гаризаларын кабул итү графигы, гаризаларны кабул итүгә җаваплы зат, аның белән элемтәгә керү өчен мәгълүмат, шулай ук гаризаларны җибәрергә мөмкин булган электрон почта адресы Инспекция тарафыннан билгеләнә һәм аның рәсми сайтында урнаштырыла.

8. Гариза һәм аңа теркәп бирелә торган документлар исемлек буенча алына, аның гаризаны һәм документларны кабул итү турында билге куелган күчермәсе гаризаны һәм документларны кабул иткән көнне кандидатка тапшырыла яисә кандидатның тиешле ризалыгын алганнан соң аңа электрон рәвештә җибәрелә.

Күпфатирлы йортларга идарә итү
эшчәнлеген лицензияләү буенча
Татарстан Республикасы
лицензия комиссиясе
формалаштыру тәртибе
турында нигезләмәгә
2 нче кушымта

Форма

Татарстан Республикасы Президенты
_______________________________
_______________________________
(кандидатның фамилиясе, исеме,
_______________________________
атасының исеме (булган очракта)

Күпфатирлы йортларга идарә итү эшчәнлеген лицензияләү буенча Татарстан Республикасы лицензия комиссиясе составына кертүгә
гариза

Мине, ________________________________________________________
(фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта), туган вакыты һәм урыны,
______________________________________________________________
паспорт белешмәләре (сериясе, номеры, кайда һәм кайсы вакытта бирелгән)
күпфатирлы йортларга идарә итү эшчәнлеген лицензияләү буенча Татарстан Республикасы лицензия комиссиясе составына кертүегезне сорыйм.

Белемем һәм квалификациямне күтәрүем турында мәгълүмат:______________________________________________________
______________________________________________________________
(белем һәм квалификация алган югары уку йорты атамасы, белем алу дәрәҗәсе, уку вакыты,
______________________________________________________________
югары белем, өстәмә белем алуны яисә яңадан әзерләү узуны раслаучы
______________________________________________________________
документлар реквизитлары)

Торак-коммуналь хуҗалыгы тармагында эш стажы ________________.

Мин__________________________________________________________
(оешманың тулы атамасы)
______________________________________________________________

вәкиле булып торам.

Мин суд тарафыннан хокуктан файдалануга сәләтсез яисә хокуктан файдалануга сәләте чикле дип табылмавымны, наркология һәм психоневрология диспансерда алкоголизмнан, наркоманлыктан, токсикоманлыктан, хроник һәм озакка сузылган психик чирләрдән дәвалану

сәбәпле исәптә тормавымны, туктатылмаган һәм ябылмаган суд хөкеме булмавын, дисквалификация рәвешендә административ җәзага тартылмавымны, Инспекция җитәкчесе белән туганлык (кодалык) мөнәсәбәтләрендә тормавымны раслыйм.

Элемтәгә керү өчен мәгълүмат: ________________________________
(телефон, факс, почта адресы,
____________________________________________________________
электрон почта адресы (булган очракта)

«Персональ белешмәләр турында» 2006 елның 27 июлендәге 152-ФЗ номерлы Федераль законның 9 статьясы нигезендә минем персональ мәгълүматларымны автоматлаштырылган рәвештә яисә автоматлаштыру чараларын кулланмыйча эшкәртүгә ризалыгымны бирәм.

Әлеге гаризаны карап тикшерү мәсьәләләре буенча электрон рәвештә мәгълүмат алуга (электрон почта адресы: ________________________) риза/ риза түгел (тиешлесенең астына сызарга).

______елның «____» ______________ /____________/___________________/
(дата) (имза, имзаны шәрехләү)